Баязитова Ф.С. Әлмәт төбәге татарлары. Казан, «Мәгариф» нәшрияты.

Бу китапта Әлмәт төбәгендәге татар авылларында тел осталарын һәм йола белгечләрен сөйләтеп, магнитофон тасмасына язып алынган гаилә һәм көнкүреш йолалары, мифология, борынгы ышануларга караган терминология, фольклор тестлары темактик яктан төркемләп бирелгән. Гасырлар тирәнлегеннән килгән, ләкин бүгенге көндә инде югалып бара торган әлеге рухи мирас халкыбызның тарихын, тел байлыгын һәм этнографиясен өйрәнүгә бер өлеш һәм файдалы кулланма булыр дип өметләнә китап авторы. Хезмәт түбәндәге бүлекләрдән гыйбарәт:

- Минзәлә сөйләше;
- Мишәр диалектына караган авыллар сөйләше (Иске Баграж-Елхово һәм Түбән Абдул); Әлмәт төбәгендәге керәшен татарлары сөйләше (Кәләй, Илтән-Бута, Кәзәбаш авыллары); Әлмәт төбәге сөйләшләрендәге көнкүреш һәм йола сүзләренең, этнографизмнарның алфавит тәртибендә бирелеше;
- файдаланылган әдәбият;
- сөйләп мәгълүматлар биргән тел осталарының һәм йола белгечләренең исемнәре.

Татар халкы һәм аның тарихи хәтере дигәндә без беренче чиратта телне һәм гореф-гадәтләрне саклауда иң зур терәк булган авылны һәм авыл халкының телен күз алдында тотабыз. Шуңа күрә авылларда сакланып калган җирле сөйләшләрне өйрәнү өчен, экспедицияләргә чыгып, анда тупланган материалларга нигезләнеп, автор бу хезмәтен укучыларга тәкъдим итте.

Зур игътибар гаилә йолаларына бирелә. Алар түбәндәге темаларга бүлеп өйрәнелә: туй йолалары һәм йола терминологиясе; бала туу белән бәйле йолалар һәм йола терминологиясе; кешене соңгы юлга озату, искә алу йолалары һәм йола терминологиясе.

Китапта ел фасыллары белән бәйле йолалар, борынгы ышанулар (мифология) һәм аларга караган сүзләр шулай ук тематик яктан берләштерелеп бирелә: кышкы йолалар һәм бәйрәмнәр, йола сүзләре; язгы-җәйге йолалар һәм бәйрәмнәр; өмәләр, аулак өйләр, утырмалар; мифология, борынгы ышанулар; ырымнар һәм им-томнар.

Татар халкының җирле сөйләшләрендә йолаларга караган терминология гаҗәп бай һәм кызыклы. Һәм бу хезмәттә бирелгән Әлмәт районы авылларында тел осталары һәм йола белгечләреннән язып алынган сөйләм үрнәкләре, халыкның хәтерендә сакланып, бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән борынгы йолалар, гореф-гадәтләр турында истәлекләр моңа дәлил булып тора.